**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЛАБЕРДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

422373 РТ, Тетюшский район,с. Алабердино,
ул. Ленина, 71

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӘТЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛАБИРДЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422373 ТР, Тәтеш районы, Алабирде авылы,
Ленин урамы, 71 йорт

тел. (84373) 5-80-37, факс 5-80-37, e-mail: Alab.Tet@tatar.ru
ОКПО 94304386, ОГРН 1061672020222, ИНН/КПП 1638005160/163801001

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**11.03.2025** **№13**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Алабирде авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләүне уздыру тәртибен раслау турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 1743 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләр турында " 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Алабирде авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ::

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Алабирде авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләүне уздыруның кушымтада бирелә торган тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенә 1 апрельгә кадәр Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Алабирде авыл җирлеге башкарма комитетына хисап елындагы һәм хисап елына кадәрге елдагы һәр салым чыгымы буенча белешмәләр җибәрүне тәкъдим итәргә:

- ташламалардан файдаланган түләүчеләр саны турында;

- Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Алабирде авыл җирлеге бюджетының төшеп кала торган керемнәре суммалары турында;

- Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Алабирде авыл җирлеге бюджетына салым чыгымнарын стимуллаштыручы һәр салым чыгымы буенча түләүчеләр тарафыннан декларацияләнгән салым күләмнәре турында.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://tetushi.tatarstan.ru/.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Җитәкче** Р.И. Хәкимов